
**Эндәшләр өйрәнү:**

1.Чыпчык, чыпчык, чык-чырык!
Җим сиптем, кил тиз очып!
2. Песнәк, песнәк, кил тизрәк
Җим сибәм сиңа әзрәк!
3. Чәүкә, чәүкә, кил чәүкә,
- Җим бирәм бер тәлинкә.
4. Күгәрченем гөр-гөр-гөр
- җим сиптем менә күр-күр!
5. Карга, карга, син кара,
Кабып кал, азык барда!
6. Саескан –ала канат,
Җим сибәм кабат-кабат!
**Бергә:** Килегез, кил кошкайлар,
Сез бит безнең дускайлар
Бакчабызга куныгыз
Көн дә кунак булыгыз.

***Бергәләп өйрәник***



***Яз***

***Әти-әниләр өчен ярдәмлек***

***(5-6 яшь)***

**Әйтемнәр**

а) Каз килсә – яз килә.
б) Апрель туса – яз була.
в) Апрель җитсә, яз җитәр,
Эреп бетеп, кар китәр.

**Тизәйткеч. [җ] авазы.**

Җы-җы-җы-җы
Яз килде җылы.

**Әйтенү «Сыерчык»**

Сыерчык, сыерчык,
Күк күлмәгең киеп чык.
Үзеңнеке булмаса,
Атаңныкын киеп чык.

**Мәкаль**

Язгы хезмәт – көзге хөрмәт.
Эчтәлеге буенча фикер алышу.

- Яз көне кешеләр нинди хезмәт башкаралар?
- Чәчүгә чыгар алдыннан нинди бәйрәм була?
- Яз көне нинди борынгы бәйрәмнәр билгеләп үтелә?

**Эндәш ятлау: «Кояш, чык!»**

Кояш, чык, чык, чык!
Майлы ботка бирермен.
Майлы ботка Казанда,
Тәти кашык базарда.
Әти китте базарга,
Тәти кашык алырга.
Тәти кашык – сабы алтын,
Безгә кирәкми салкын.

**Зиһен сынаш уены «Кап та коп»**

Балалар, бер-берсенең баш бармакларын учлаган килеш, йодрыкларын йодрык өстенә куеп, кулларын бергәләп күтәреп - төшереп, түбәндәге такмазаны әйтәләр:

Без, без, без идек,
Без унике кыз идек.
Базга төштек, бал ашадык,
Келәткә кердек, май каптык,
Кап та коп, Тимер туп,
Авызыңны ач та йом!
Бар да берьюлы авызларын йомалар. Кем дә кем беренче булып авызын ачса яисә көлеп җибәрсә, шул балага җәза бирелә. Ул яз турында табышмаклар, мәкальләр, сынамышлар әйтә.

**«Яз һәм балалар» җырлы-хәрәкәтле уены**

Балалар: Исәнме, яз, матур яз!
Безне сагынып килдеңме?
Агачларга, куакларга
Яшел чуклар элдеңме?
Яз: Саумы, нәни дусларым!
Сезне сагынып килдем мин.
Сезгә аяз көннәр дә,
Яңгыр да китердем мин.
Балалар: Яңгыр яу, яу, яу,
Бар табигать юынсын,
Тирә-як көлеп торсын.
Яңгыр: «Яу, яу»- дип яңгыр телисез,
Ә үзегез качып йөрисез.